# Яшь каләмче

Яр Чаллы шәһәре, 40 нчы урта мәктәп Декабрь 2024 .

Бу айда…. Тиздән Яңа ел килеп житә.

Бу айда... укучыларның шәһәр туры олимпиадалары тәмам

Бу айда... безнең мәктәп укучылары 2025нче елны каршылап, күңелле бәйрәм иттеләр

Бу айда... укучылар фәнни-гамәли конференциядә катнаштылар

Бу айда... 2 нче чирек тәмам була

Бу айда... ур-ра, каникуллар башлана






## Поздравляем!

Закончился муниципальный этап Всероссийской олимпиады школьников. Поздравляем всех призеров олимпиады, благодарим всех участников олимпиады.

Призерами стали:

- по биологии – Чурбанов Тихон 9г класс, Ивлева Софья 7бкласс (учитель Шарипова Т.Х.)
- по родному татарскому языку - Ибрагимова Самира 5в класс (учитель Тазиева Р.Р.)
- по татарскому языку в русскоязычных группах – Митякина Софья 5 д класс, Корепанова Анастасия 9б класс, Анисифорова Аделия 10 класс (учитель Арсланова Л.Х.)
- по русскому языку - Фролов Иван 7а класс (учитель Гилязетдинова И. М.)
- по английскому языку - Ильясова Эвелина 7б класс (учитель Фархутдинова А. Н.)

Желаем дальнейших успехов!








# Поздравляем!!!

***Успех - это личный стандарт, достижение самого высокого, что есть в нас, становление всем, кем мы можем быть.***




Поздравляем учителя английского языка Ахмадиеву Фариду Фаритовну с заслуженной победой в номинации «Мастерство и вдохновение» в Муниципальном этапе ВСЕРОССИЙСКОГО КОНКУРСА «Учитель года России».

Желаем крепкого здоровья, творческих успехов!

**Преграды в пути-
нам не помеха!
Всегда и везде
мы добьемся успеха!**

14 декабря прошел очный тур V Всероссийской научно-практической конференции «На крыле науки» . Наши учащиеся стали победителями и призерами.

Победители:
Рыскалова В. (учитель Кузнецова. А.В.)
Якименко В., 9 класс (учитель ШариповаТ.Х.)

Призеры:
Волкова М. 6 класс (учитель Антипова И.З.),
Сафина З. 7д класс (учитель Тазиева Р.Р.)
Ахатова Д. 9 класс (учитель Арсланова Л.Х.),
Сорокина А. 8 класс (учитель Кадырова И. З.)

Поздравляем учащихся и их учителей!
Желаем дальнейших побед! Молодцы!







«Успех должен быть доступен каждому ребенку. Если ребенку удается добиться успеха в школе, то у него есть все шансы на успех в жизни».

Уильям Глассер








# Укучылар иҗаты

## 2 нче сыйныфлар ни диләр? Әәә, менә үзләре дә...




Минем яраткан дәресләрем бик күп. Алар: татар теле , технология, математика, инглиз теле, уку, рәсем сәнгате. Без ул дәресләрдә язабыз, укыйбыз һәм төрле темалар өйрәнәбез. Мин ул темалар белән кызыксынам Болар минем яраткан дәресләрем. Ул дәресләрне мин игътибар белән тыңлыйм, дүртлеләр, бишлеләр алам. Яхшы аңлагач, яхшы билгеләр алуы да күңелле була.**Миннебаев Айдын- Кенан. 4а сыйныфы**

Мин рәсем дәресләрен бик яратам. Бу дәрес безгә атнага бер тапкыр үткәрелә.Укытучыбыз безгә башта ничек итеп рәсемне дөрес итеп ясарга икәнен аңлата. Аннары без бик тырышып, укытучы өйрәткәннәрне кабатлыйбыз. Миңа авыр булды Ләкин мин рәсемне яхшы итеп ясый алдым. Миңа бу дәрес ошый, чөнки мин үзем дә рәсем ясарга яратам һәм, рәсем ясаганда, минем кәефем күтәрелә. **Риана,4а сыйныфы**

Мин физкультура дәресен яратам. Без анда йөгерәбез һәм уйныйбыз. Тагын төрле ярышларда катнашабыз, бик күп күнегүләр ясыйбыз. Эстафеталарда җиңеп чыгарга тырышабыз. Җиңеп чыгу өчен көчле һәм җитез булырга кирәк. Спорт шуңа ярдәм итә. Минем уйлавымча, безнең сыйныф укучылары барысы да физкультураны ярата дыр, мөгаен. **Әхмәдиева Инзилә. 4а сыйныфы**

Минем яраткан дәресем физкультура. Аны Михаил Михайлович алып бара. Дәрестә без зарядка ясыйбыз, уйныйбыз, ярышабыз.Кайбер дәресләрдә нормативлар тапшырабыз. Безне укытучыбыз баскетбол, волейбол, футбол уйнарга өйрәтә. Шуңа күрә мин физкультурага яратып йөрим. Бу дәрес бик тиз һәм күңелле үтә. **Вафина Айзилә. 4а сыйныфы**

Минем яраткан дәресем - физкультура. Физкультура миңа бик ошый, чөнки без анда спорт белән шөгыльләнәбез, уеннар уйныйбыз. Йөгерү буенча ярышлар, башка бик күп төрле уеннарда катнашабыз. Дәрестә күп хәрәкәт итәбез. Дәрестән мин бик арып чыгам. Дәрес тәмамланыр алдыннан укытучыбыз безгә уеннар уйната. Физкультура дәресе миңа сәламәтлегемне ныгытырга ярдәм итә**. Вафин Аяз,4а сыйныфы**

Минем яраткан мәктәп предметы- рәсем сәнгате. Мин кечкенә чакта ук рәсем ясарга ярата идем. Хәзер дә буш вакытым булды исә, рәсем ясыйм. Бигрәк тә табигатьне сурәтләргә яратам, чөнки табигать бик матур! Мин пейзаж, хайван рәсемнәрен ясыйм Күпчелек рәсемнәрне гуашь белән буйыйм. Рәсемнәр өчен пумала, кайчакта карандаш, су, гуашь, кәгазь алам. Укытучым миңа гел бишле куя һәм “молодец!” дип мактый. Әгәр минем альбомым бетә икән, мин яңасын алам. Ә искесен, үземнең бала чактагы рәсемнәремне үскәч карармын дип саклыйм.

Мин рәссам булырга хыялланам. Минем ясаган рәсемнәремне карагач, хәзер дә кайберәүләр мине рәссам дип атыйлар инде. Рәссам булуның авырлыгын аңлыйм, ләкин мин һәрвакыт матур итеп рәсем ясарга, үз хоббиемне югалтмаска тырышачакмын. **Хөсәенова Розалина, 4а сыйныфы**

Минем яраткан дәресем - рәсем дәресе. Без ул дәрестә төрле рәсемнәр ясыйбыз, бу бик авыр дәресләрдән соң баш миен ял иттерә. Миңа ул дәрес тагын шуның өчен бик ошый, чөнки укытучыбыз Гөлназ Рифатовна дәрескә бик матур картиналар сайлый. Дәрестә без кайчакта буяулар, кайчакта карандашлар белән рәсем ясыйбыз. Кайчакта табигать, кайчакта башка төрле нәрсәләрне сурәтлибез. Рәсем буенча минем билгеләрем һәрчак “5” ле була. Гадәттә, ел ахырында без ирекле темага ясыйбыз. Мин рәсем дәресен бик яратам, ул минем өчен иң рәхәт предмет. **Авзалов Рамазан, 4б сыйныфы**




Минем яраткан дәресем- татар теле. Татар теле дәресендә мин яңа сүзләр өйрәнәм, әкиятләр һәм шигырьләр укыйм. Минем укытучы теманы әйбәт аңлата. Мин татар теле дәресенә бик тә шатланып йөрим .

Татарча күбрәк белү өчен, өйдә әбием белән татарча сөйләшәм.

**Мухаметова Элина, 4б сыйныфы**

# Их , күңелле дәресләр!



Мәктәптә минем яраткан дәресләрем бик күп, әмма иң ярткаными сынлы сәнгать дәресе. Мин рәсем ясарга бик яратам. Бу дәрестә мин яраткан эшем белән шөгыльләнә алам. Аның өчен яхшы билгеләр дә алам. Мин бик матур ясый алмыйм, әмма минем өчен эш процессы кызыклы. Рәсем ясаганда, фантазиямне куллана алам. Мине рәсем ясарга өйрәткән өчен укытучыма бик рәхмәтлемен. **Шакирова Самирә, 4б сыйныфы**

Мәктәптә яраткан фәннәрем күп. Ин яраткан фәнем — физкультура. Бу дәрескә мин бик теләп йөрим. Минем тормышымда спорт зур роль уйный. Физкультурада без зарядка ясыйбыз, төрле хәрәкәтчән уеннар уйныйбыз. Кышын чаңгыда шуабыз. Физкультура – сәламәтлекне ныгытырга мөмкинлек бирә.
**Мостафин Камил, 4б сыйныфы**

Минем яраткан дәресем — математика. Миңа ул ошый, чөнки без төрле мисаллар һәм бурычлар хәл итәбез. Без яңа темалар һәм бурычларны хәл итүнең яңа ысуллары белән танышабыз. Теманы үзләштергән саен, аны мөстәкыйль эш ярдәмендә тикшерәбез. Чирек (яки бер ел) узгач, контроль эш башкарабыз. Анда без чирек буенча биремнәре үтибез, укытучы аларны тикшерә. Минем билгеләр кайвакыт "дүрт"ле була, тик, нигездә, "биш"ле генә. Шулай булгач, бу минем яраткан дәресем, ул бик кызыклы!
Мостафина Жәмилә, 4 сыйныфы

Минем яраткан дәресем - татар теле. Бу дәрес миңа татар телен яхшырак белергә ярдәм итә. Дәрестә мин яңа сүзләр өйрәнәм. Өйдә әбием белән татар телендә сөйләшәм. Татар теле укытучысына дәрестә дөрес җавап бирсәм, бик шатланам. Бу дәрестә мин курыкмыйча җавап бирә алам, дөрес булмаса да, укытучы мине тиргәми, чөнки мин тырышам. **Хәйруллина Эмилия, 4б сыйныфы**

Минем яраткан дәресем — математика. Ул миңа ошый, чонки мин санарга һәм мәсьәләләр чишәргә яратам. Без дәрестә күнегүләр чишәбез һәм сызымнар сызабыз. Миңа күбрәк тапкырлау һәм бүлүгә бирелгән мәсьәләләр ошый. Яратканга, математика дәресе бик күңелле үтә.
Быел математика буенча олимпиадада катнаштым. Анда бик күп мәктәпләрдән укучылар килгән иде. **Хәйруллина Амелия 4б сыйныфы**

***2 нче сыйныф укучыларына укуларында уңышлар , туган телебезне ратуларын телибез.Туган телдә сөйләшергә, язарга өйрәткән укытучылары Нәфисә Ризатдиновнага зур рәхмәт.***

**Безнең мәктәп китапханәсе төрле кызыклы, кирәкле китапларга бик бай. Китапханәче Эльвира Равилевна укучылар белән төрле кызыклы дәресләр үткәрә, яңа китаплар, газета –журналлар белән таныштыра.**





2 в сыйныф укучылары укытучылары Рузалия Рәвгатовна белән китапханәдә булдылар. Туган телләрендә китаплар укыдылар, өйләрендә укырга дип татарча китаплар алдылар.





Ә 1 нче А сыйныф укучылары китапханәгә сыйныф җитәкчеләре белән килделәр. Эльвира Равилевна аларны китапханәдәге тәртипләр белән таныштырды. Китапны яратырга, аның белән бик сакчыл булырга тиешлекне аңлатты. Төрле әкиятләр буенча сораулар бирде. Беренчелар бик кызыксынучаннар, күп әкиятләр беләләр икән.

**"Яшь каләмче" түгәрәге**